**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2019 елның 21 февраленнән №8-РС

# КАРАР

**Район Советының 2016 елның 13 декабреннән №69-РС “Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2007 елның 2 мартыннан № 25-ФЗ “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законны, 2017 елның 1 июленнән №132-ФЗ “Россия Федерациясенең кайбер закон актларына дәүләт хезмәте мәгълүматлары өлкәсендә коррупцион хокук бозулар эшләгәнлектән ышанычны югалту белән бәйле төстә эштән азат итү сыйфатында җәза куллану турында дәүләт мәгълүмати системасына урнаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законны, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “ Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июненнән № 50-ЗРТ Кодексы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә Лаеш муниципаль район Советы карар бирде:

1.Район Советының 2016 елның 13 декабреннән № 69-РС “Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы Карарына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**